СОВЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

**Яңасала авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**« 16 » апрель 2019 ел** **№ 23**

**2018 елның 21 декабрендә 20 нче номерлы Яңасала авыл җирлеге Советы карары белән расланган Арча муниципаль районы «Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

2018 елның 27 декабрендәге 559-ФЗ номерлы Федераль закон белән «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 7 нче маддәсенә, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы Федераль законның 13 нче маддәсенә үзгәрешләр кертелү сәбәпле Яңасала авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. 2018 елның 21 декаберендә 20 нче номерлы Яңасала авыл җирлеге Советы карары белән расланган Арча муниципаль районы «Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

1) 10 нчы бүлекнең 10.5 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10.5 муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе, муниципаль берәмлек башлыгы, җирле хакимият башлыгы, билгеләнгән муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын туганлык мөнәсәбәтләрендә (әти-әниләре, хатыны, ире, балалары, абыйлары, апалары, энеләре, сеңелләре, хатыны яки иренең әти-әнисе, аларның балалары, балаларының ире яки хатыны) торган очракта гражданин муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе, рәисе урынбасары һәм аудиторы вазыйфаларына билгеләнә, ә муниципаль хезмәткәр муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе, рәисе урынбасары һәм аудиторы вазыйфаларын алыштыра алмый»;

2) 11 нче бүлекнең 11.1 пункты 2 нче подпунктында «кооперативлар, бакча, яшелчә бакчасы, дача кулланучылар» сүзләрен алып ташларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында «Җирлекләр» (arsk.tatarstan.ru) бүлегендә бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңасала авыл җирлеге
башлыгы Сафин А.И.